**ИСПОЛКОМ АПАСТОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422350, пгт. Апастово, улица Советская, д.2

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422350, штп. Апас, Советская урамы, 2 йорт

тел.: (84376) 2-13-52, факс: 2-19-27, e-mail: apast@tatar.ru, http://apastovo.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ 265 от 19.11.2024

**«Татарстан Республикасы Апас муниципаль районында административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген раслау хакында» карарга үзгәрешләр кертү турында**

Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексы, «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында " 30.07.2010 елгы 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ**:

1. Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Башкарма комитетының " Татарстан Республикасы Апас муниципаль районында административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген раслау хакында» 2024 елның 01 октябрендәге 240 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә::

кушымтада 24 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| 24. | 3.16 маддә. Түләүле муниципаль парковкалардан (парковка урыннарыннан)файдалану тәртибен бозу | Апас муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары;<br><br>Апас муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы |

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Җитәкче**

**Б.Н.Әхмәтҗанов**